| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.05.2023 Олы Кайбыч ав. № 182

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 гыйнварындагы 57 номерлы карары белән расланган Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану һәм 2023 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2022 елның 21 ноябрендәге 448-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар тоту тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 28 гыйнварындагы 57 номерлы карары белән расланган Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фонды күләме «Тиешле елга Кайбыч муниципаль районы бюджеты турында» Кайбыч муниципаль районы Советы карары белән билгеләнә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А. Н. Макаров